**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

____________　　　　ПГ-39 26.12.2025　　　　№____

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законы, район Уставы, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталына, Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Ачык тыңлаулар турында мәгълүматны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында, Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
4. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көн дип билгеләргә.

- ачык тыңлаулары үткәрү вакыты – 2026 елның 15 гыйнвары:
- 10.00 сәгатьтә, үткәрү урыны: Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл Башкарма комитеты бинасы, адресы: 423740, ТР, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт;

5. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе К.Н. Әхмәдгалиевны ачык тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
6. Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
____________ 2025 ел, №___
кушымта

АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты (алга таба генераль план) буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатыннан эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук генераль план проекты буенча халыкның фикерен исәпкә алуны җайга сала.

1. Генераль план проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы халыкның генераль план проекты буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуы һәм авыл җирлеге халкының генераль план проекты буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Авыл җирлеге генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дүш. – җом. 9.00 дән 16:00 гә кадәр, (төшке тәнәфес 11.30 дан 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты fgis.economy.gov.ru территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында бастырылып чыгарылырга тиеш..

5. Авыл җирлеге генераль планы проекты буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү **26.12.2025 елдан 14.01.2026 елга кадәр**, шул исәптән, түбәндәге адрес буенча башкарыла: 423740, ТР, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 йорт, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы.

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру, шулай ук генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлауларны уздыру өчен җаваплы кеше гамәлгә ашыра.

7. Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итүне ачык тыңлаулар секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы, секретарь тарафыннан катнашучыларны теркәү үткәрелә. Теркәү битендә катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- төп доклад өчен докладчыга 20 минуттан артык вакыт бирелми;
- Генераль план проектын тикшерү чыгышлары өчен 3 минуттан артык вакыт бирелми;
- репликалар һәм искәрмәләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

11. Ачык тыңлаулар үткәргәндә секретарь генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып бара. Беркетмәгә ачык тыңлауларны оештыручы һәм секретарь кул куя.

12. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар үткәрелгән көннән соң 2 көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә әзерли, анда мәҗбүри рәвештә күрсәтелә:

- ачык тыңлауга чыгарылган сорауның исеме;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

14. Нәтиҗә ачык тыңлауларны оештыручы тарафыннан имзалана һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Актаныш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында мәҗбүри рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.